**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указлары нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Транспорт куркынычсызлыгы буенча ведомствоара комиссиясе турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-715 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 27 ноябрендәге ПУ-1088 номерлы, 2015 елның 20 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-24 номерлы, 2016 елның 15 ноябрендәге ПУ-1006 номерлы һәм 2021 елның 20 мартындагы ПУ-236 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Транспорт куркынычсызлыгы буенча ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәдә:

4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның бишенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Транспорт куркынычсызлыгы буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Л.Р. Габдерахмановны, Ә.Г. Галәвовны, А.В. Егоровны, А.А. Ибәтуллинны, И.А. Купцовны, А.Н. Муллинны, Ф.Г. Хәмидуллинны, М.Н. Хисаметдиновны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Әхмәтҗанов Марсель Мансур улын – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Бобков Алексей Александровичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлекчәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Гарипов Рөстәм Рамил улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Комиссия секретаре итеп раслап, Захватова Мария Андреевнаны – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге башлыгын;

Романова Наталия Вячеславовнаны – Транспорт өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел буе федераль округы буенча төбәкара территориаль идарәсе дәүләт авиация күзәтчелеге Казан территориаль бүлеге башлыгын (килешү буенча);

Комиссия рәисе урынбасары итеп раслап, Садыйков Айрат Халит улын – Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасарын;

Хәйруллин Марс Ринат улын – «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Куйбышев тимер юллары башлыгы урынбасарын (Казан территориаль идарәсе буенча) (килешү буенча);

Черемнов Александр Павловичны – «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Горький тимер юллары башлыгы урынбасарын (Казан территориаль идарәсе буенча) (килешү буенча);

Шакиров Илдар Сәетҗан улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Э.Ю. Даниловның – «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча)»;

И.Г. Минһаҗевның – «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ регионы автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесе башлыгы (килешү буенча)»;

Р.В. Рамазановның – «Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел буе федераль округы буенча төбәкара территориаль идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2014 елның 13 декабрендәге 707 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 30 июлендәге 439 номерлы, 2016 елның 5 апрелендәге 221 номерлы, 2017 елның 9 гыйнварындагы 2 номерлы,

2017 елның 3 июнендәге 342 номерлы, 2017 елның 16 декабрендәге 731 номерлы, 2018 елның 6 сентябрендәге 294 номерлы, 2020 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 398 номерлы һәм 2021 елның 29 декабрендәге 347 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмәдә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы каршындагы финанс базарлары өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр эшләү буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – Эш төркеме) составында:

Эш төркеме составыннан Е.Е. Варфоломееваны, П.Н. Громушкинны, И.В. Козачекны, Ю.И. Наумованы, Б.Н. Разиновны, М.В. Трофимованы чыгарырга;

Эш төркеме составына кертергә:

Булатова Юлия Анатольевнаны – Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Ибраһимов Илнур Габделхәй улын – Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасарын (килешү буенча);

Ибәтуллин Альберт Рәис улын – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башкару производствосын оештыру бүлеге башлыгын (килешү буенча);

Никитин Юрий Сергеевичны – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесен (килешү буенча);

Фәйзрахманов Рушан Васил улын – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча).

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеге оештыру һәм

Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 15 июнендәге ПУ-550 номерлы Указының 2 һәм 3 пунктлары;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеген оештыру һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 21 июлендәге ПУ-668 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 3 пунктындагы «в» пунктчасы.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 22 август
№ 574